| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАП-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2024 ел. Потап-Томбарлы авылы № 124

Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 13.04.2018 ел, № 56 «Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.09.2024 ел, № 820 карары нигезендә Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 13.04.2018 ел, № 56 карарына кертергә «Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» (Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советының 12.09.2020 № 139, 28.09.2022 № 53, 20.12.2022 № 64, 28.03.2023 № 69, 28.06.2024 № 113карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме «Потап-Томбарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретареның вазыйфаи оклады күләменә туры китереп исәпләнә, аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 13 990 сум тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык, Совет Рәисе
Потап-Томбарлы авыл җирлеге С. А. Козлова